РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Село Янурусово, улица Ленина, дом 43в, 423370 Телефон 4-10-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

Ленин урамы,43 в йорт, Янурыс авылы,
423370 Телефон: 4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

**01 февраль 2016 ел.**

**КАРАР**
**№8**

**Янурыс авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 26 гыйнварындагы 5 номерлы карары нигезендәге Янурыс авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Янурыс авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2016 елның 20 мартына Янурыс авыл хуҗалыгы территориясендә гражданнарның үзара салымын алып бару мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:
«2016 елда үзара салым акчаларын Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә кертүгә, I төркем инвалидлар һәм ялгыз карт гражданнар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге бүлек студентларыннан тыш алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез килешәсезме:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;

- ял вакытын оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

- җирлек территориясендә физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм тотуны да кертеп);

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту . -җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләүне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

-каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу; - җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру; - Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иректе керүен тәэмин итүне дә кертеп.

әйе　　　　　　　　　　　　　　　юк

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Совет рәисе,
Янурыс авыл җирлеге башлыгы　　　　А.Ә.Мөхәмәдиева